| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СПАССКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
| **Р Е Ш Е Н И Е** | | **К А Р А Р** |
| **6 февраль 2023 ел** | Болгар ш. | **№ 26-5** |

2023 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Спас муниципаль районы Уставы нигезендә, Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча җирле үзидарә органнарында һәм Спас муниципаль районының муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пункты Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Спас муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Спас муниципаль районы башлыгы урынбасары С.И. Тюнев